Татарстан Республикасы Хисап палатасы

# Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2010 елдагы эшчәнлеге турында

# ХИСАП

Казан – 2011 ел

# Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2010 елдагы эшчәнлеге турында хисап

Эчтәлек

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре ..... 3

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге ..... 7

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге ..... 11

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрендәге тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек ..... 25

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек ..... 27

Эшчәнлектә хәбәрдарлык ..... 28

# Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2010 елдагы эшчәнлеге турында хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эшчәнлеге турында хисап “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Законның 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта Хисап палатасының 2010 елга закон тарафыннан билгеләнгән функцияләрне һәм бурычларны үтәү буенча эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

## Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре

Тикшерү чаралары республика бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджетын формалаштыру һәм үтәү буенча беренчел, оператив һәм дәвамлы тикшерү кысаларында үткәрелде.

2010 елда Хисап палатасы тарафыннан 155 тикшерү чарасы уздырылды.




Хисап палатасы тарафыннан **гомуми күләме 2 984 585,9 мең сумлык финанс бозулары ачыкланды.** Шул исәптән, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча – 2 145 486 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары – 645 258,2 мең сум, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды – 5 129,8 мең сум, бюджеттан тыш чаралар буенча 188 711,9 мең сумлык бозу табылган.

**2010 елда чараларны кулланганда Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган финанс бозулар төзелеше (финанслау чыганаклары киселешендә)**




Тикшерү нәтиҗәләре буенча 2010 елда бюджет чараларын төп кулланучыларга, бюджет процессының башка катнашучыларына табылган бозуларны бетерү буенча чаралар кұрү өчен 54 күрсәтмә һәм 121 мәгълүмати хат юлланды.

Хокук саклау органнары һәм дәүләт финанс тикшерүе, заказ урнаштыру өлкәсендә тикшерү органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе турында Килешү нигезендә Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Прокуратурасына 48 тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча материаллар юлланды. Республика шәһәр һәм районнары прокурорлары тарафыннан башкарма хакимият органнары, оешма һәм учреждение җитәкчләренә бюджет законнарын бозуны юкка чыгару турында 30 күрсәтмә юлланды.

Үткәрелгән тикшерү чаралары материаллары буенча 95 вазифаи һәм юридик зат җаваплылыкка тартылды. Шул исәптән мировой судьялар һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы карарлары нигезендә бюджет акчаларын максаттан тыш куллану фактлары буенча административ җаваплылыкка 23 зат тартылды (гомумән алганда, 300 мең сум күләмендә штраф салынды), Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча 72 вазифа заты дисциплинар җаваплылыкка, шул исәптән 6 вазифа заты вазифаларыннан азат ителде. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә Хисап палатасы үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча бер җинаять эше ачылды.

Дәүләт заказларын урнаштыру өлкәсендә бозулар ачыкланган 19 тикшерү чарасы буенча мәгълүмат Монополиягә каршы Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә юлланды. Хисап палатасы тарафыннан юлланган

тикшерү материаллары нәтиҗәләре буенча вазифа затларына карата 5 административ эш ачылды.

Тикшерү нәтиҗәләре нигезендә гомум күләме **1 750 696,8** мең сум чара **кире кайтарылды** һәм ачыкланган бозулар буенча **чаралар күрелде**:

- бюджет чараларын максаттан тыш куллану фактлары буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 90 251,4 мең сум,
- бозуларның башка төрләре буенча Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына 160 254,4 мең сум чара **кире кайтарылды**;
- бюджет чараларын кулланганда һәм башка финанс бозулары вакытында ачыкланган җитешсезлекләрне (нәтиҗәсез эшчәнлекне) юкка чыгару буенча 1 500 191 мең сум күләмендә чаралар күрелде.

**Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан 2007-2010 елларда үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча бозулар күләме, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга кире кайтарылган чаралар һәм күрелгән чаралар динамикасы**




Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 17, шул исәптән Татарстан Республикасы законнары проектларына – 10, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында 6 бәяләмә, шулай ук 2009 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисапка бәяләмә тәкъдим ителде.

Хисап палатасы эшчәнлеген характерлаучы төп күрсәткечләр түбәндәге таблицада тәкъдим ителгән.

| Күрсәткеч атамасы | 2007 ел | 2008 ел | 2009 ел | 2010 ел |
|---|---|---|---|---|
| **I. Экспертиза-аналитика эшчәнлеге** | | | | |
| Үткәрелгән экспертиза-аналитика чараларының гомуми саны | 60 | 70 | 100 | 104 |
| Әзерләнгән эксперт бәяләмәләре | 19 | 21 | 26 | 33 |
| Әзерләнгән методик документлар | 12 | 3 | 3 | 3 |
| **II. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге** | | | | |
| Тикшерү-ревизия чараларын үткәргәндә колачланган объектлар саны (берәмлекләрдә) | 510 | 443 | 464 | 470 |
| Ачыкланган бозулар күләме (мең сумнарда), | 1 625 522,3 | 4 538 492,6 | 2 201 772,8 | 2 984 585,9 |
| шул исәптән: | | | | |
| - бюджет чараларын максаттан тыш файдалану (мең сумнарда) | 28 866,0 | 87 082,7 | 60 873,1 | 96 629,0 |
| - бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану (мең сумнарда) | 184 798,1 | 533 139,0 | 133 048,3 | 365 140,3 |
| **III. Тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру** | | | | |
| Юлланган күрсәтмә һәм билгеләмәләр | 40 | 42 | 40 | 54 |
| Бюджетка кире кайтарылган чаралар һәм күрелгән чаралар (мең сумнарда) | 484 115,3 | 573 089,3 | 1 454 450,0 | 1 750 696,8 |
| Прокуратура һәм хокук саклау органнарына үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча юлланган материаллар саны (берәмлекләрдә) | 28 | 46 | 51 | 57 |
| Хисап палатасы тикшергән материаллар буенча суд һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан административ җаваплылыкка тарту турында карар саны | 44 | 106 | 66 | 71 |
| ТР Хисап палатасы материаллары буенча ачылган җинаять эшләре саны | - | 1 | 3 | 1 |

Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турындагы” Законы һәм Хисап палатасының эш регламенты нигезендә, Хисап палатасының эчке планлаштыру һәм эш оештыру мәсьәләләре, шулай ук тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләре Хисап палатасы Коллегиясе утырышларында каралды. Коллегия тарафыннан 34 карар кабул ителде, 74 мәсьәлә каралды.

# Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

Экспертиза-аналитика эшчәнлегендә Хисап палатасы өчен Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджетын формалаштыру һәм үтәү, киләсе финанс елына һәм планлы вакыт өчен бюджет проектына, бюджет турындагы законга үзгәрешләр кертү турында закон проектларына бәяләмә әзерләү мәсьәләләре өстенлекле булып тора.

2010 елда 104 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде. Аларның нәтиҗәсе Хисап палатасы бәяләмәләрен әзерләгәндә һәм тикшерү-ревизия чараларын планлаштырганда кулланылды. 33 эксперт бәяләмәсе, республика бюджеты чараларын төп куллanучыларның еллык бюджет хисабын тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча 31 бәяләмә, 66 аналитик документ әзерләнде.




**Беренчел тикшерү** кысаларында хисап елында Татарстан Республикасының 8 закон проектына, шул исәптән 2011 елга һәм 2012 һәм 2013 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды (алга таба – ММИ Фонды) бюджеты турында һәм 2010 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында һәм ММИ Фонды бюджеты турындагы законнарга үзгәрешләр кертү турында законнар проектларына, экспертиза үткәрелде.

Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре билгеләнгән вакытта Татарстан

Республикасы Дәүләт Советына тапшырылды.

Хисап палатасы бәяләмәләрендә күрсәтелгән кисәтү һәм тәкъдимнәр закон проектларын икенче укылышта карау барышында исәпкә алынды.

**“2011 елга һәм 2012 һәм 2013 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында”** закон проектына бәяләмәдә закон проектының үзенчәлекле яклары күрсәтелгән – өчеллык бюджетны планлаштыру принципларын торгызу, чыгымнарның бюджет классификациясендәге үзгәрешләре, бюджет чыгымнарын классификацияләүнең тиешле бүлекләре буенча бюджетара трансфертларны бүлү, бюджет чыгымнарын формалаштырганда программалы-максатчан алымны алга таба да кертү.

Эспертиза нәтиҗәләре нигезендә закон проектын тәкъдим иткән вакытка 2011 елда финансланырга тиешле озакка сузылган максатчан программаларның билгеләнгән тәртиптә расланмаганлыгы билгеләп үтелде.

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советына Юлламасында республикада инновацион эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпләп баруның эффектлы системасы юклыгы билгеләп үтелгән иде. Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп күрсәткечләре составында республика икътисадының инновацион өлешен характерлаучы күрсәткечләрне исәпкә алу юлы тәкъдим ителде.

Киләсе елга федераль бюджет проекты күрсәткечләрен исәпкә алып, кире кайтарылмый торган керемнәрнең аерым төрләре буенча күләмне тәгаенләү тәкъдим ителде.

**“2011 елга һәм 2012 һәм 2013 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы Мәҗбирү медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты турында”** закон проектына бәяләмәдә ММИ иминиятләштерү кертемнәре килү, ММИ база программасы кысаларында мәҗбүри медицина иминиятләштерү территориаль программасын үтәүгә ММИ Федераль фондыннан уртак керемгә һәм дотацияләргә салым буенча Фонд бюджетының керем өлешендә күрсәткечләрне тәгаенләү кирәклеге билгеләп үтелә. Шулай ук, муниципаль берәмлекләрдән килүче бюджетара трансфертларны закон проекты тарафыннан каралган күләмдә раслаган очракта, ММИ Фонды бюджетының баланслылыгы югалу куркынычы барлыгы күрсәтелә.

**2010 елга Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты турындагы** законнарга үзгәрешләр кертү нигездә керемнәрнең фаразланган күрсәткечләрен тәгаенләү, ел барышында күчерелгән федераль бюджет чараларын беркетү, Россия Федерациясе Пенсия фонды һәм Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышу фонды

дәүләт корпорациясе бюджетларыннан килгән кире кайтарылмый торган керемнәр күләме, шулай ук бюджет ассигнованиеләрен чыгымнарның аерым төрләре буенча тәгаенләү һәм яңадан бүлү белән аңлатылды.

Үзгәрешләр кертү турындагы закон проектларына бәяләмәләрдә хисап елында бюджет күрсәткечләренең чынлыкта үтәлгән күләмен искә алып тәгаенләү буенча кисәтү һәм тәкъдимнәр ясалды.

**Агымдагы тикшерү** кысаларында ай саен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенә анализ үткәрелде.

Агымдагы тикшерү күләм һәм төзелеш буенча республика бюджетының керем һәм чыгым маддәләрен вакытында үтәүне, башкарылган чыгымнарның законлылыгын, дәүләт бурычы хәлен, бюджет алучыларның дебитор һәм кредит бурычлары күләмен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитлар буенча бурыч күләмен, республика бюджетының вакытлыча буш торган чараларын банк депозитына урнаштырудан килгән керемнәрне, өстенлекле илкүләм проектларны, республика максатчан программаларын тормышка ашыруны тикшерүне үз эченә алды.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджетының агымдагы үтәлешен тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисаплары, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе мәгълүматлары, республика бюджеты чараларын төп кулланучылар һәм ММИ Фонды хисаплары нигезендә федераль казначылык һәм статистика органнары мәгълүматларын кулланып үткәрелде.

Агымдагы тикшерү кысаларында шулай ук Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты, федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары үтәлешенә, республикада күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү программасын тормышка ашыруга, Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү буенча чараларга, Татарстан Республикасында социаль-икътисадый хәлне, Россиядәге фонд базары хәлен мониторинглау тормышка ашырылды.

Татарстан Республикасы бюджетын, ММИ Фонды бюджетын үтәү буенча агымдагы тикшерү, шулай ук читкә чыгып тикшерү нәтиҗәләре Хисап палатасы бәяләмәләрендә чагылыш тапты. Бәяләмәләр, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97(1) маддәсе нигезендә, квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

2010 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында бәяләмәдә аталган Хисап палатасы кисәтүләре искә алынып, бюджет турындагы законга тиешле үзгәрешләр кертелде – муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитлары бирү күләмнәре һәм вакытлары тәгаенләнде.

**Дәвамлы тикшерү** кысаларында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 109 маддәсе, “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турындагы” Татарстан Республикасы Законының 9 маддәсе нигезендә **2009 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисап**ка тышкы яктан тикшерү үткәрелде.

2009 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы Хисапта чагылыш тапкан керемнәр, чыгымнар, бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча республика бюджеты үтәлеше күрсәткечләренең дөреслеге Татарстан Республикасы бюджеты чараларының төп администраторларының еллык бюджет хисабын тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча расланды.

Тикшерү нәтиҗәләре, 2009 елда бюджетны үтәгән чакта бюджет законнары нормаларын, бюджет турындагы закон нигезләмәләрен бозу очраклары булуын, финанслау булган хәлдә дә максатчан программалар чараларының тулы күләмдә тормышка ашырылмавын, бюджет чараларын максаттан тыш һәм нәтиҗәсез куллануны күрсәтте. Тикшерү кысаларында республика милкендә булган мөлкәтне куллануның нәтиҗәлелеген арттыру хисабына бюджет чыгымнарын оптимизацияләү резервлары һәм бюджетның салым булмаган керемнәрен арттыру резервлары барлыгы ачыкланды.

Еллык бюджет хисабын тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча аерым министрлыкларга мәгълүмати хатлар юлланды.

**“2009 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында”** Татарстан Республикасы законы проектына һәм аның белән бер үк вакытта тәкъдим ителгән материалларга экспертиза ясалды. Аның барышында закон проектында чагылыш тапкан республика бюджеты үтәлеше күрсәткечләренең 2009 ел бюджеты үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләре белән туры килүе ачыкланды.

**“2009 ел өчен Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты үтәлеше турындагы”** Татарстан Республикасы законы проектын экспертизалау нәтиҗәләре буенча закон проекты күрсәткечләренең ММИ Фонды бюджетының чынлыктагы үтәлешенә һәм бюджет хисабы мәгълүматлары белән тәңгәл килүе ачыкланды.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә 16 югары дотацияле муниципаль берәмлек бюджетлары үтәлеше турындагы еллык хисапка тышкы тикшерү үткәрелде. Шулай ук тышкы тикшерү кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү мәсьәләләре каралды.

Тикшерү нәтиҗәләре 2009 елда җирле бюджетларны үтәгәндә бюджет законнары нормаларын, бюджет, финанс һәм бюджет дисциплинасы турындагы нигезләмәләрне бозу очраклары, киләсе финанс елы йөкләмәләре буенча түләүләр хисабына чыгымнар ясау, бюджет классификациясе таләпләрен истә тотмаган хәлдә бюджет хисабын формалаштыру фактлары булуын күрсәтә.

Хисап палатасы бәяләмәләре муниципаль район башлыкларына юлланды.

Дәвамлы тикшерү кысаларында 2009 елда хезмәт базарындагы киеренкелекне киметү буенча чаралар күрүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны анализлау үткәрелде. Анализ нәтиҗәләре буенча программага кертелгән чараларның тулы күләмдә финанслануы һәм үтәлүе һәм хисап елында 297 386 гражданга ярдәм күрсәтелүе ачыкланды.

## Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2010 елда Хисап палатасы тарафыннан 51 тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде, 470 объект тикшерелде. Тикшерелгән чаралар күләме **35 723,4** млн. сум.

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр үткәргән вакытта түбәндәге бозулар ачыкланды:

- 96 629 мең сумлык бюджет чараларын максаттан тыш куллану;
- Бюджет чараларын куллангандагы җитешсезлекләр (нәтиҗәсез эшчәнлек) – 365 140,3 мең сум;
- Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен сатып алуларны тормышка ашыруда киткән бозулар – 664 179,8 мең сум;
- Дәүләт (муниципаль) мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге бозулар – 174 876,4 мең сум;
- Бухгалтерлык исәбен алып бару һәм хисап төзү тәртибен бозу – 900 224,8 мең сум;
- Кредит ресурсларын җәлеп итү, куллану һәм кире кайтару белән бәйле бозулар – 15 389 мең сум;
- Башка төр финанс бозулар – 768 146,6 мең сум (Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына сатып алынган милек, җиһаз, төп чаралар

һәм товар-матди байлыкларны сатып алу, тапшыру, аерымланган хисап алып бару өлешендәге бозулар, расланган лимиттан күбрәк күләмдә бюджет йөкләмәләре алу, чараларны озак вакыт кулланмый тору һәм башкалар).

**2010 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозулар төзелеше (мең сумнарда)**




Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре, 2009 ел өчен бюджет хисабын тышкы яктан тикшерү буенча чаралар республиканың 15 министрлыгы һәм ведомствосына караган учреждение һәм оешмаларында, 9 муниципаль берәмлектә үткәрелде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр тарафыннан 2006-2008 елларда һәм 2009 елның 9 аенда **энергия ресурсларын кулланганда бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит** үткәрде.

Сайлап алынган тематиканың актуальлеге 2009 елның 23 ноябрендә кабул ителгән “Энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 261-ФЗ

номерлы Федераль закон таләпләре белән аңлатыла. Әлеге закон буенча биш ел дәвамында бюджет учреждениеләре тарафыннан энергия ресурсларын куллануны унбиш проценттан да кимрәк булмаган күләмгә киметү каралган.

Үткәрелгән аудит Татарстан Республикасында энергияне саклау буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өчен кирәк булган шартлар булуын күрсәтте. Энергияне саклау һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге өлкәсендәге норматив документлар гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп эшләнгән.

Шуның белән беррәттән, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль сәясәт министрлыгы тарафыннан энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге тармак программасын тормышка ашыру энергияне куллану күләменең кимүенә һәм күрсәтелгән максатларга чыгымнарны оптимизацияләүгә сизелерлек тәэсир ясамады.

2006-2009 елларда коммуналь хезмәтләр өчен түләргә чаралар ихтыяҗын планлаштыру Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелүче индекс-дефляторлар нигезендә тормышка ашырылды. Бу очракта тиешле вакытка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган финанс чыгымнары нормативлары һәм энергияне куллануның натураль нормалары, ә энергия аудитын үткән учреждениеләр буенча – энергия тикшерүе нәтиҗәләре буенча учреждениеләргә бирелгән энергия паспортларында күрсәтелгән нормативлар исәпкә алынмады.

Ведомствога караган тикшерелгән учреждениеләрдә, энергия ресурсларын кулланганда һәм энергияне саклау буенча чаралар үткәргәндә, Татарстан Республикасы бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеге тулы күләмдә тәэмин ителмәгән, исәп приборлары белән җиһазландыруның һәм аларны куллануның булган дәрәҗәсе энергия ресурсларын куллануны тикшерүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итмәгән, үткәрелгән энергетик тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ясалган тәкъдимнәр тулы күләмдә үтәлмәгән, кулланылмый торган бүлмәләрне тоту буенча коммуналь чыгымнар түләнгән.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләрнең коммуналь хезмәтләрен түләүгә, шулай ук энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге тармак программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән тикшерелгән бюджет чараларының 843 млн. сум тәшкил иткән гомуми күләменнән аудит барышында ачыкланган бозулар күләме – 177,2 млн. сум, шул исәптән чараларны нәтиҗәсез куллану 126 млн. сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләрнең энергия ресурсларын кулланганда бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеге аудиты нәтиҗәләре

турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына юлланды, 2010 елның 22 октябрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы утырышында, шулай ук 2010 елның 1 декабрендә Казанда узган “Бюджет оешмаларында һәм учреждениеләрендә энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру” семинар-киңәшмәсендә каралды.

Россия-Британия проекты кысаларында Хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасы белән берлектә “Сәламәтлек” өстенлекле илкүләм проекты кысаларында Россия Федерациясе субъектларына кайтарылучы **медицина җиһазларын кулланунын** нәтиҗәлелеге аудитын үткәрүдә катнашты.

Тикшерү чаралары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында һәм республиканың 42 дәвалау учреждениесендә үткәрелде.

2006-2010 елларда Татарстанның сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен диагностика җиһазлары сатып алуга федераль һәм республика бюджетларыннан 4,37 млрд. сум бүлеп бирелде, бу медицина учреждениеләрен модернизацияләүне үткәрүне рөхсәт итте. Мәсәлән, маммографлар белән тәэмин ителеш 2005 елдагы 15 берәмлектән 2009 елда 34 берәмлеккә, УЗИ-аппаратлар – 429 берәмлектән 532гә җитте. Нәтиҗәдә үткәрелүче тикшеренүләр саны шәһәр һәм авыл җирлегендә уртача 20%ка артты.

Тик “Сәламәтлек” өстенлекле илкүләм проектын тормышка ашыруның нәтиҗәлелегенең планлы күрсәткече – көтү вакытының өч көнгә кадәр кыскаруы – республикада аерым диагностика хезмәтләре буенча ирешелмәгән. Мәсәлән, аерым учреждениеләрдә кан тамырларын ультратавыш белән тикшерүне көтү вакыты айдан артыкка сузыла.

Моннан тыш, кайтарылган җиһазның бәяләмәләре һәр вакытта да дәвалау-диагностика процессы таләпләре белән туры килми, аерым очракларда комплекслы тикшеренүләр үткәрү өчен өстәмә җиһазлар һәм башка кирәк-яраклар сатып алу кирәк була. Мәсәлән, маммографны эксплуатацияләү өчен проявкалаучы машина кирәк, LOGIQ BOOK XP, LOGIQ 100 ультратавышлы аппаратлары чикләнгән мөмкинлекләргә ия – кан тамырларын тикшерүне үткәрергә мөмкинлек бирми.

Тикшерү үткәрелгән учреждениеләрнең күбесендә медицина персоналы белән комплектлаштырылып бетелмәү күзәтелә. Мәсәлән, Яшел Үзәннең балалар тудыру йортында, тикшеренүләр үткәрү өчен белгеч булмау сәбәпле, 4 айга якын вакыт куелган Nemio ультратавышлы система файдаланылмаган.

Куелган һәм файдалануга тапшырылган маммографларның һәм флюорографларның бер өлеше тулы куәткә эшләми. Бу исә аларны куллануның нәтиҗәлелеге кимүгә китерә. Шулай, Яшел Үзән, Кукмара, Чистай

сырхауханәләре маммографларында көненә уртача 3 тикшерү үткәрелә (ягъни норманың 25%ы).

Халыкның күрсәтелүче медицина хезмәтләренең сыйфаты һәм очсызлыгы белән канәгатьлеген ачыклау максаты белән республика халкы арасында сораштыру үткәрелде. Сораштыруда 36 муниципаль берәмлектән 1 меңнән артык кеше катнашты. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге хәзерге хәлне халык тулаем алганда уңай бәяли. Шул ук вакытта халык медицина хезмәтләре өчен түләү кирәклеге турында кайгырту белдерә. Аерым алганда, респондентларның 10%ы – лаборатор тикшерүләр һәм рентгенография өчен, 24%ы УЗИ өчен түләгән.

Нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәсе буенча әзерләнгән тикшерелүче объектларның эшчәнлеген камилләштерү һәм бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлланды.

Уртак аудит нәтиҗәләре Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясенең 2010 елның ноябрендәге утырышында расланды.

Нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре 2010 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы Хисап палатасында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Сәламәтлек саклау идарәсе вәкилләре катнашында узган брифингта яңгырады.

Татарстан Республикасы Дәүләт советы йөкләмәсе буенча Хисап палатасы тарафыннан 2008-2010 елларда **яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә** бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Күрсәтелгән максатка чыгымнар 2008-2010 елларга “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасын (алга таба - Программа) тормышка ашыру кысаларында гамәлдә булып, 1 969 921,5 мең сум, шул исәптән республика бюджеты чаралары хисабына 652 927,8 мең сум тәшкил итте.

2010 елда җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртырга мохтаҗ 10 385 гаилә чиратта тора иде. Программаны тормышка ашыру кысаларында торак шартларын 2 453 яшь гаилә яхшыртты.

Программаны тормышка ашыру механизмын анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тарафыннан 2008-2010 елларга “Татарстан Республикасының яшь гаиләләрен торак белән тәэмин итү” максатчан программасында катнашучыларның үзара тәэсир итешү тәртибе эшләнде һәм расланды.

Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча хисап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлланды.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына сугару эшләрен үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү кысаларында Хисап палатасы тарафыннан 2007-2009 елларга "Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә җирләрне тамырдан яхшырту буенча сугару эшләре" республика макстачан программасының төп индикаторларын башкаруны анализлау үткәрелде.

Тикшерү хисап чорында Татарстан Республикасы бюджетыннан программа буенча каралган чараларны тормышка ашыруга 201,9 млн. сум бүленгәнлеген күрсәтте. Бозуларның гомум күләме 17 млн. сум тәшкил итте, шул исәптән бюджет чараларын нәтиҗәсез куллану, башкарылган эшләрнең бәясен арттыру очраклары ачыкланды.

Тикшерү чоры өчен программаларның төп индикаторларын үтәүне анализлау гомумән алганда Программаларны финанслау арткан чакта ел саен расланучы күрсәткечләрнең кими баруын ачыклады. Шулай, 2007 елда сугару җирләрен кире торгызу 2 350 га мәйданда каралган булса, 2009 елда – 1 626 га, ягъни 44%ка кимегән. Җирләрне су һәм җил эрозиясеннән саклау буенча күрсәкечнең кимүе 65% тәшкил итте, ә авыл хуҗалыгы әйләнешенә авыл хуҗалыгы җир-суларын җәлеп итү – 90%. Шул вакытта 2009 елда бүлеп бирелгән бюджет чаралары күләме, 2007 ел белән чагыштырганда, 1 гектар сугару җиренә исәпләгәндә 4 мәртәбә артты.

Сугару эшләре өчен яраклы техниканың гомуми саны соңгы ел эчендә – 32%ка, сугару җаһазлары саны – 17%ка кимеде. Аерым хуҗалыкларда булган сугару техникасы кулланылмый. Шулай, 2009 елда Балтач муниципаль районының "Дуслык" ҖЧҖ сатып алган 1,2 млн. сумлык ике юллы су сиптергечләр 2010 елның июлендә узган тикшерү вакытына кулланылмаган иде. Сугару системалары куелган җир участогында авыл хуҗалыгы культуралары чәчелмәгән.

Хисап елында 2006 елга Татарстан Республикасы Капитал кертемнәре программасы кысаларында финансланган төзелеп беткән аерым объектларны **инвентаризацияләү һәм куллану** мәсьәләсе буенча тикшерү чарасы үткәрелде.

Тикшерү тарафыннан 2010 елның 22 мартына "Татсельжилкомхоз" ААҖ балансында гомуми бәясе 45 232,7 мең сумлык әлеге акционерлык җәмгыятенең уставлы капиталында Татарстан Республикасы өлешен арттырмыйча Татарстан

Республикасы бюджеты чаралары хисабына төзелгән 7 тәмамланган объект ачыкланды.

Дәүләт милкенең коммерциячел оешма балансында булуы үзен акламый һәм әлеге байлыкны югалту куркынычы белән бәйле. Элек акционерлык җәмгыяте заказчы булган эшләр тәмамланган, объектлар тапшырылган һәм һичшиксез эксплуатацияләүче оешмаларга бирелергә тиеш.

Килеп чыккан хәл бюджет чараларын үзләштерү һәм Капиталь кертемнәр программасы чаралары үтәү нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан җитәрлек контрольдә тотмау белән бәйле.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелеп беткән объектларның бер өлеше муниципаль берәмлекләр балансына бирелде.

Хисап палатасы тарафыннан 2008-2009 елларда Яр Чаллы шәһәренең **льготалы категория гражданнарына транспорт хезмәте күрсәтүне** тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган чараларны бүлү буенча методик тәкъдимнәрнең тулысы белән үтәлмәве ачыкланды. Транспорт оешмалары өчен хисап тоту формасы эшләнмәгән. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә муниципаль заказлар төрле бозулар белән тормышка ашырылган: килешү шартлары үзгәртелгән, бәйге үткәрмичә килешүләр төзелгән. Тиешле санкция булмаган хәлдә – тиешле килешүләр төземичә – пассажир йөртү очраклары ачыкланды.

Характерлы бозулар һәм җитешсезлекләр буенча мәгълүмат закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына юлланды.

Тикшерү чарасы барышында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгымнарны компенсацияләү размерын исәпләү тәртибен башкару Регламенты расланды һәм муниципалитетларга җибәрелде.

Хисап чорында мәгариф учреждениеләрендә **янгынга каршы чаралар**га бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән тикшерү чарасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство программасында янгынга каршы җиһаз куюга мохтаҗ учреждениеләр исемлеге юклыкны, финанслау күләменең, индикатив күрсәткечләрнең билгеләнмәгән булуын күрсәтте.

Янгыннан саклау системасын монтажлауга лотларның беренчел бәясен формалаштырганда җиһазлар бәясен арттыру фактлары ачыкланды. нәтиҗәдә дәүләт контрактлары югары бәя буенча килешенгән һәм түләнгән.

Янгын сигнализацияләренә техник яктан хезмәт күрсәтү буенча Мәгариф учреждениеләренең үзләре төзегән килешүләре һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт контрактлары арасындагы бәяләр аермалыгы 170%ка җитә.

Тикшерү барышында гомуми бәясе 107 821,4 мең сумлык куелган янгын сигнализацияләре системасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан алга таба хезмәт күрсәтү өчен белем бирү учреждениеләренә бирелде.

2007-2009 елларга **Җирләрне геологик яктан өйрәнү** һәм Татарстан Республикасы минераль-чимал базасын кабат җитештерү **программасын** тормышка ашыруга бүленеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү барышында 68 047,4 мең сумлык бозу, шул исәптән бюджет чараларын кулланган чакта 10 647,6 мең сумлык нәтиҗәсез эшчәнлек алып бару ачыкланды. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан бер елдан артык вакыт буе максатчан чараларның 8 034,2 мең сумлык калдыгы кулланылмаганлыгы, шулай ук чынлыкта төзелмәгән бинаның проект-смета документациясе (аны төзү буенча чыгымнар 2 613,4 мең сум тәшкил иткән) кирәксез калганлыгы ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 12 мартында кабул ителгән 131 номерлы карары белән 8 034,2 мең сумлык кулланылмаган калдык хисабына финансланучы өстәмә чаралар Программага кертелде.

Хисап чорында Татарстан Республикасы Хисап палатасы **күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны** үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануга мониторинг ясауны дәвам итте.

Апас, Чүпрәле, Кукмара, Мамадыш, Мөслим, Менделеевск һәм Түбән Кама муниципаль районнарында, шулай ук Казан шәһәренең Яңа Савин районында үткәрелгән тикшерү чаралары ярдәмендә 122 445,6 мең сум күләмендә бозулар ачыкланды.

Подряд оешмаларын аванслау лимитларын арттыру, килешү йөкләмәләрен үтәү вакытын бозу, проект-смета документациясен әзерләгән чактагы җитешсезлекләр һәм башка бозулар табылды.

Хәзергә хәтле узучы ремонтның сыйфаты буенча кисәтүләр һәм арттырылган күләмдәге эш өчен түләү урын алып тора. Күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган урыннарның (кибет, офислар һ.б.) хуҗаларыннан капиталь ремонт үткәрүгә чаралар алу белән проблема килеп чыга. Аерым очракларда эш башкаруга кирәкле эш тәҗрибәсе һәм үзенең матди-техник базасы булмаган оешмалар җәлеп ителгән.

2008 һәм 2009 еллар өчен Түбән Кама муниципаль районында муниципаль адреслы программаны үтәүне сайлап тикшерү тарафыннан күпфатирлы торак йортларда капиталь ремонт үткәргәндә гомуми бәясе 129 880,1 мең сумлык кайнар һәм салкын су белән тәэмин ителүне хисаплау приборлары һәм җылылык энергиясе белән идарә итү төенләнеше куелганлыгы ачыкланды. Шул ук вакытта тикшерү чарасын үткәргән вакытка (2010 елның сентябре) өйләрдә әле 2008 һәм 2009 елда ук куелган җылылык энергиясе санаучылары эксплуатацияләнә башламаган. Тикшерү барышында җылылык энергиясе санаучылары кулланыла башлады.

Күп очракта капиталь ремонтның ачыкланган җитешсезлекләре подряд оешмалары тарафыннан инде тикшерү барышында ук юкка чыгарылды.

Күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү буенча чаралар йомгаклары 2010 елның июлендә видеоконференция режимында узган республика киңәшмәсендә муниципаль берәмлекләрнең башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә җиткерелде.

2008-2009 елларда һәм 2010 елның I яртыеллыгында мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, яшьләр сәясәте өлкәсендә **грантлар** системасының эшләү нәтиҗәлелеген тикшерү 1 455,4 мең сумлык финанс бозулары ачыклады, шул исәптән чараларны нәтиҗәсез куллану – 981,4 мең сум, чынлыкта башкарылмаган төзелеш-монтажлау эшләре өчен түләү – 474 мең сум. Тикшерү барышында 870 мең сумлык бозулар юкка чыгарылды.

Татарстан Республикасында кабул ителгән социаль яктан мөһим инициативаларга һәм проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендә норматив хокукый актлар грантлар системасының нәтиҗәлелеген тәэмин итә.

Шуның белән бергә яшьләр сәясәте өлкәсендә грант алучыларны сайлау буенча чараларны оештыру һәм үткәрүдә бушлай (кире кайтарылмый торган) бюджет субсидияләрен бүлгән вакытта коррупция куркынычын булдырмау тәэмин ителми.

Кайбер очракларда Россия һәм чит илнең мәгариф һәм фәнни оешмаларында кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм стажировкалауга грантлар Республика бәйге комиссиясе карарын исәпкә алмыйча бирелгән. Грант алучыларны аларның

вазифасы бурычына туры килмәгән белгечлеккә юллау (“Инглиз телен укыту” программасы буенча математика факультеты, дөнья икътисады кафедрасы, аграр университет укытучылары укыган) фактлары ачыкланды, яшь үзенчәлеге каралмаган – укуга пенсия яшенә җиткән затлар юлланган, дәүләт ярдәме чаралары грант алучыларның базар бәясеннән ике мәртәбәгә артык бәядәге бина арендалауга киткән чыгымнарын каплауга юлланылган. Грант хисабына чынлыкта башкарылмаган төзелеш-монтажлау эшләре өчен түләнгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Тәкъдимнамәләр юлланды.

Хисап палатасы тарафыннан 2008-2010 елларда “Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе” дәүләт учреждениесенә (“Главтатдортранс” ДУ) **Шәле-Саескан тавы автомобиль юлын төзү өчен** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү үткәрелде.

Тикшерү барышында материалларга бәяне чынлыкта подряд оешмаларының үзләре куюы, һәм, ахыргы чиктә, юл төзелешенә чараларны чыгымлау күләмен билгеләве ачыкланды. Смета исәпләүләрендә матди ресурсларга карата төгәл нигезләмәләре булмаган бәяләр куллану акланмаган бюджет чыгымнарына китерә.

Шәле-Саекскан тавы автоюлы буенча смета исәпләүләрендә ком-гравий кушылмасына арттырып куелган бәяләр кулланылган. Нәтиҗәдә бу объект буенча смета бәясен арттыру 49 млн. сумнан артып киткән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юл төзелеше өчен матди ресурсларга бәя кую һәм куллануның гамәлдәге тәртибен яңадан карап чыгу тәъдиме белән хат юлланды.

Тикшерү эшчәнлеге кысаларында Хисап палатасы тарафыннан **коррупция күренешләре күзәтелү ихтималы** белән бәйле булган түбәндәге юнәлешләргә аеруча игътибар бирелә: бюджет чараларын бүлү һәм куллану, дәүләт программаларын тормышка ашыру, дәүләт (муниципаль) милкен, җир участокларын куллану һ.б.

Республика һәм муниципаль милектә булган байлыкны куллану өлешендә Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр

нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы Коллегиясе утырышында каралды.

Коррупциягә каршы тору өлкәсендәге юнәлешләрнең берсе булып дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыру системасында бюджет чараларын куллануны тикшерү тора.

Хисап палатасы комплекслы тикшерү чараларын үткәрү барышында дәүләт һәм муниципаль сатып алуларны регламентлаучы законнарны гомум күләме 664 млн. сумлык бозу ачыклады.

2007-2009 елларда **Казан метрополитенын төзүгә** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәсе буенча дәүләт сатып алуларын тормышка ашырганда 436 955,9 мең сумлык бозу ачыкланды. Шулай, "Җир асты транспорты корылмаларын төзү дирекциясе" муниципаль казна предприятиесе тарафыннан "Хәрәкәт" системасы өчен 80 млн. сумлык 204 берәмлек җиһаз кайтаруга бәйге үткәрелде. Бәйге йомгаклары буенча "Төгәл механика" ФТИ (НИИ "Точной механики") ААҖ белән шул ук бәягә 94 берәмлек җиһаз кайтару турында контракт төзелде. Чынлыкта 52,3 млн. сумга 74 берәмлек җиһаз кайтартылды.

Электр депосы өчен 19 056,9 мең сумга 40 берәмлек технологик җиһаз кайтартуга бәйге үткәрү барышында да шундый ук хәл урнашты. Бәйге җиңүчесе "Барс-сервис" ҖЧҖ тарафыннан 18 653,8 мең сумга 26 берәмлек, шул исәптән 3,5 млн. сумнан артык бәягә заказчы тарафыннан соралмаган 7 берәмлек җиһаз кайтарырга тәкъдим ителде.

Дәүләт ихтыяҗы өчен гомум күләме 86 698,9 мең сумлык товар кайтартуга, эш башкаруга, хезмәт күрсәтүгә заказлар урнаштыру өлкәсендәге законнарны бозулар шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында (24 049,8 мең сум) һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында (62 649,1 мең сум) үткәрелгән тикшерүләр барышында ачыкланды.

2010 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны алу шартларын үтәүне тикшерү, аларны максатчан һәм нәтиҗәле куллану, җирле бюджет үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча тикшерү Апас, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Чүпрәле, Мөслим һәм Түбән Кама муниципаль районнарында үткәрелде.

Бозуларның гомуми күләме 688 959,1 мең сум тәшкил итте. Җирле бюджет чараларын максаттан тыш куллану, муниципаль милек белән нәтиҗәсез идарә итү, муниципаль заказларны урнаштыру процедурасын һәм контракт шартларын үтәүне

бозу, күпфатирлы торак йортларны капиталь ремонтлау буенча сыйфатсыз эшләр үткәрүләр ачыкланды.

Муниципаль милекне кулланганда бозулар – төп чаралар объектларын муниципаль милек Реестрына кертмәү, муниципаль милектән бушлай куллануга килешү төзү, җир участоклары өчен аренда түләвен киметү һәм исәпләп бетермәү, кадастр бәясеннән сизелерлек кимрәк булган бәягә авыл хуҗалыгы билгеләнешендә булган җирләрне сату – Апас (7,4 млн. сум), Кукмара (29,1 млн. сум), Мамадыш (100,8%), Менделеевск (16,9 млн. сум), Мөслим (33,8 млн. сум) муниципаль районнарында ачыкланды.

Түбән Кама муниципаль районында үткәрелгән тикшерү чарасы барышында муниципаль милек белән идарә итү һәм тормышка ашыруда җирле үзидарә органнарының нәтиҗәсез эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 107 374,2 мең сумлык бозулар ачыкланды. Аренда түләве һәм мөлкәтне сатудан килергә тиешле чаралар 47 315,8 мең сум тәшкил итә.

Мәсәлән, 2005 елда “Бызовский” ҖЧҖ белән сәүдә үзәге төзүгә җир участогы арендалау турында килешү төзелгән. Алыш-биреш нәтиҗәләре буенча аренда бәясе елына 1 926,1 мең сум күләмендә билгеләнгән. 2006 елда сәүдә үзәген төзү вакытына җир участогын арендалау бәясе елына 766,6 мең сумга кадәр төшерелгән. Чынлыкта сәүдә үзәген төзү башкарылмаган, ә күрсәтелгән җир участогында эшләп торучы базар урнашкан, ягъни җир участогы аны тәкъдим итү шартларын бозып файдаланылган. Җирле бюджетка керем килмәүнең гомум күләме 16 604,3 мең сумнан артыгракны тәшкил итә.

Аерым очракларда муниципаль милек коммерциячел оешмаларга нигезсез шартларда бушлай тәкъдим ителгән.

Татарстан Республикасының табигатьне саклау чаралары программалары хисабына 2004 елдан каты көнкүреш калдыклары полигоны төзү башкарылды, шул исәптән 2008 елда 8 165,8 мең сум түләнде. 2008 елның июлендә объект эксплуатациягә тапшырылды. Шуның белән бергә каты көнкүреш калдыклары полигоны (агымдагы бәяләрдә гомуми күләме – 56 496 мең сум) муниципаль милек реестрына кертелмәгән, кулланылышка тапшыруга килешүләр төзелмәгән. Түбән Кама шәһәре учреждениеләре һәм оешмаларына каты көнкүреш калдыкларын полигонда урнаштыруга тәкъдим ителгән контрактлар буенча калдыкларны кабул итү һәм җыю өчен түләү “Калдыкларны яңадан эшләп чыгаруның экологик системалары” Идарә компаниясе” ҖЧҖнда (“ЭкСПО” ИК” ҖЧҖ) башкарыла.

Шулай итеп, хокукны билгеләүче документлар булмаган чакта, коммерциячел оешма милектән файдаланган һәм калдыкларны утильләштерү өчен түләү алган. 2009 ел һәм 2010 елның I яртыеллыгы өчен бары тик бюджет учреждениеләреннән генә килгән нигезсез керем 397,1 мең сум тәшкил итә.

2010 елның сентябрендә үткән тикшерү нәтиҗәләре буенча гомум мәйданы 23 га ике җир участогы “ЭкСПО” ИК” ҖЧҖ коммерциячел оешмасы тарафыннан Түбән Кама районының Башкарма комитетына каты көнкүреш калдыклары полигонын эксплуатацияләү өчен бушлай бирелде. 2010 елның ноябрендә муниципаль берәмлек артыннан полигонга карата милек хокукы рәсмиләштерелде.

Моннан тыш, авыл хуҗалыгы җирләрен максаттан тыш куллану фактлары табылды.

2008 елда Түбән Кама Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән Кызыл Чишмә авылы территориясеннән шәхси эшмәкәргә 6,5 га мәйданда авыл хуҗалыгы билгеләнешендә булган җир участогы бирелгән. Җир участогын авыл хуҗалыгы билгеләнешеннән башка категориягә күчерүне раслаучы документлар тикшерүчеләргә тәкъдим ителмәде, аренды килешүе төзелмәгән, шул ук вакытта күрсәтелгән җир участогында төрле җәмгыять туклануы предприятиеләре урын алган, берәмтекләп, шул исәптән алкогольле эчемлекләр сату оештырылган.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Түбән Кама Башкарма комитеты тарафыннан 349 102,5 мең сумлык чаралар күрелде, шул исәптән: бюджетка 175 436,2 мең сум кире торгызылды, 173 666,3 мең сумлык бозулар юкка чыгарылган.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе** нигезендә 2010 елда Хисап палатасы тарафыннан аренда өчен түләүләр килүләрне, бюджет алучыларның кредит бурычы хәлен тикшерү башкарылды.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгында Татарстан Республикасы Прокуратурасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты белән берлектә үткәрелгән Татарстан Республикасының дәүләт милкендә булган байлыкларны кулланган өчен аренда түләүләренең республика бюджетына килүен тәэмин итүдә законны үтәү мәсьәләсе буенча тикшерү чарасы барышында 2009 елда һәм 2010 елның 9 аенда Татарстан Республикасы бюджетына 2 649,2 мең сум күләмендә акча килеп җитмәгәнлеге ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына дәүләт милкен кулланганда табылган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча тәкъдим кертелгән.

“Балалар республика клиник хастаханәсе” сәламәтлек саклау ДУ тикшерү барышында 2010 елның 1 гыйнвареннән урнашуның законлылыгын раслаучы документлар булмаган хәлдә хастаханәнең 378,6 кв.м. мәйданын “Ак Барс Медицина” ҖЧҖ биләгәнлеген ачыклады.

Шул вакытта “Балалар республика клиник хастаханәсе” сәламәтлек саклау ДУ Татарстан Республикасы 2010 елның 1 октябренә карата Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына әлеге мәйданны тоту буенча коммуналь хезмәтләр өчен гомум күләме 120,9 мең сум акча түләгән.

Тикшерү барышында “Ак Барс Медицина” ҖЧҖ әлеге чыгымнарны “Балалар республика клиник хастаханәсе” сәламәтлек саклау ДУ тулы күләмдә компенсацияләде.

Муниципаль милекне кулланудан килгән аренда түләүләре, муниципаль бюджет алучыларының кредит бурычы хәле белән бәйле мәсьәләләр үткәрелгән комплекслы тикшерүләр барышында каралды.

Чүпрәле муниципаль районында уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча 2010 елның 1 июленә карата вакытында түләнмәгән кредит бурычы 10 548,2 мең сум, ягъни кредит бурычының гомуми күләмендә 79,8%ын тәшкил итте.

Кредит бурычы төзелешендә иң зур өлеш бюджетка түләүләр буенча исәпләүләргә туры килә. 2010 елның 1 июленә карата хәлдә алар 10 353,9 мең сум, ягъни кредит бурычының гомуми күләмендә 78,3%ын тәшкил итте

Муниципаль милекне арендалау килешүләрен сайлап алып тикшерү аренда килешүләренең кайберләре буенча милек өчен аренда түләвен исәпләү инфляция коэффициенты үзгәрешләрен исәпкә алмыйча тормышка ашырылуын ачыклады. 2008-2009 еллар һәм 2010 елның I яртыеллыгы өчен җирле бюджетка акчаларның килеп җитмәве 68,7 мең сум тәшкил итте.

Менделеев һәм Апас муниципаль районнарында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү вакытында җир участоклары һәм милек өчен аренда түләве буенча Менделеев муниципаль районы бюджетына акча килеп бетмәү 871,7 мең сум тәшкил иткәнлеге, Апас муниципаль районында җир һәм милекне арендалау буенча вакытында түләнмәгән 48,6 мең сум күләмендәге бурычны кире кайтару буенча чаралар күрелмәгәнлеге ачыкланды.

2009 елның 1 гыйнвареннән 2010 елның 1 гыйнваренә кадәрге вакыт эчендә Менделеев муниципаль районында кредит бурычы 3 285,3 мең сумнан 4 108,3 мең сумга арткан (25,1%ка). Вакытында капланмаган бурыч 2 984,3 мең сум, ягъни 73%. Кредит бурычы төзелешендә бюджетка түләүләр буенча исәпләүләр 47% тәшкил итә.

2010 елда уздырылган тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чараларының йомгаклау документлары Хисап палатасы мәгълүмати бюллетеньнарының 21-24 саннарында урын алды, шулай ук Хисап палатасының http://www.sprt.ru интернет сайтында урнаштырылды.

## Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрендәге тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек

2010 елда Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (АКСОР) һәм Россия муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эш дәвам итте.

Октябрьдә Казанда 2013 елда Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасына объектлар төзү һәм уздыруга әзерлекне финанслауда бюджет чараларын һәм башка чыганакларны куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы коллегияләренең уртак утырышы узды. 2011 елда да Универсиаданы үткәрүгә әзерлек һәм объектлар төзүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү буенча уртак эшне дәвам итү турында карар кабул ителде.

**Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе** кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең XV һәм XVI конференцияләрендә, дәүләт финанс тикшерүен камилләштерү мәсьәләләренә багышланган кайбер фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм видеокиңәшмәләрдә катнашты.

2010 елның гыйнварендә Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе Президиумы утырышында Идел буе федераль округында АКСОР бүлеге Рәисе А.И.Демидовның 2006-2009 елларда дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерү системасын төзү һәм ныгыту буенча Ассоциация бүлегенең эшчәнлек тәҗрибәсе турында мәгълүматы тыңланды. АКСОР Президиумы Идел буе федераль округындагы Ассоциация бүлеге эшчәнлеген хуплады һәм федераль округларда эшләп килүче АКСОР бүлекләренең җитәкчеләренә Идел буе округы бүлегенең эш тәҗрибәсен гамәлдә кулланырга тәкъдим итте.

Россия Федерациясе Хисап палатасының системалы анализлау дәүләт фәнни-гамәли институты эш планы нигезендә Татарстан Республикасы Хисап палатасының эш төркеме “Тикшерү-хисап органының эшчәнлеген оештыру” дәүләт финанс тикшерүе стандартын әзерләүдә катнашты. Алга таба стандарт Россия субъектларының тикшерү-хисап органнары эшчәнлегендә куллану өчен тәкъдим ителәчәк.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре Мәскәүдә (Россия Федерациясе Хисап палатасында) һәм Лондонда (Бөекбританиянең Аудит буенча дәүләт идарәсендә) узган сәламәтлек саклау өлкәсендә нәтиҗәлелек аудитының методологиясен һәм гамәлиятен үстерү мәсьәләләре буенча Россия-Британия семинарларында катнашты.

2010 елның октябрендә Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан “Тышкы финанс тикшерүен үстерүнең өстенлекле юнәлеше буларак бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү” дигән темага семинар уздырылды.

Семинарда Хисап палатасы хезмәткәрләре, министрлыклар, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Татарстан Республикасында финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең территориаль идарәсе вәкилләре, республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап палаталары җитәкчеләре катнашты. Семинарда лекцияләр циклы белән Россия Федерациясе Хисап палатасының Җыелма департаментын методологик яктан тәэмин итү бүлеге башлыгы, нәтиҗәлелек аудитының методологиясен эшләүчеләрнең берсе А.Н.Саунин чыгыш ясады.

**Халыкара хезмәттәшлек** кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Россия делегациясе составында 2010 елның октябрендә Лондонда узган Европаның региональ тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (ЕВРОРАИ) Конгрессында катнашты.

2010 елда **Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы** кысаларында муниципаль дәрәҗәдә финанс тикшерүенең нәтиҗәле системасын формалаштыруга ярдәм күрсәтү, тикшерү-хисап органнарының үзара хезмәттәшлек итүен тәэмин итү буенча эш дәвам итте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары вәкилләре Идел буе федераль округында АКСОР Бүлекчәсе кысаларында үткәрелүче тикшерү-хисап органнарының эшчәнлеген норматив-хокукый яктан тәэмин итү һәм муниципаль тышкы финанс тикшерүен үстерү мәсьәләләре буенча регионара семинарларда катнашты.

2010 елда Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы кысаларында беренче мәртәбә “Татарстан Республикасының иң яхшы финанс тикшерүчесе” дигән исемгә бәйге үткәрелде.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг ясалды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати, шул исәптән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудитны оештыру һәм үткәрү буенча ярдәм күрсәтелде. Совет эшчәнлеге турында мәгълүмат, норматив һәм методик документлар, квалиикация күтәрү курслары турында мәгълүмат Хисап палатасының (http://www.sprt.ru) һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының (http://www.ksort.ru) рәсми сайтларында урнаштырылды.

## Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек

2010 елда Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан эш дәвам ителде.

Республика территориясендә финанс тикшерүе органнарының үзара хезмәттәшлеге бюджет чараларын куллану мәсьәләләре буенча уртак тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү ярдәмендә, шул исәптән Тикшерү чараларының җыелма планы, үткәрелгән тикшерүләр буенча Бердәм автоматлаштырылган мәгълүмат базасын эшләтү, финанс-бюджет өлкәсендәге бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында республика министрлыклары, ведомстволары һәм муниципаль берәмлекләренә юллана торган кайбер методик документларда (дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе барышында ачыкланган бозулар һәм кимчелекләр Классификаторы, дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан ачыкланучы бозулар һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә) типик бозуларны һәм кимчелекләрне унификацияләү нигезендә тәэмин ителде. Хисап палатасы, Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Финанс-бюджет күзәтчелеге дәүләт хезмәтенең Территориаль Идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бюджет законнарын бозу буенча ачыкланган мәгълүматлар квартал саен гомумиләштерелде.

Татарстан Республикасы Прокуратурасы мөрәҗәгатьләре нигезендә, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыру өлкәсендә законнарны үтәү; күпфатирлы йортларда һәм социаль өлкә учреждениеләрендә капиталь ремонт үткәрү; Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм яшь гаиләләрне, авыл җирлегендә яшәүче яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү; Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган байлыкны кулланган өчен республика бюджетына аренда түләүләре килү мәсьәләләре буенча 10 тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә 4 тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде.

## Эшчәнлектә хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасының Коллегия, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары һәрдаим массакүләм матбугат чараларында, шул исәптән федераль басмаларда яктыртылып торды.

2010 елда массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмалар, журналлар, газеталар һәм телевидениедә) Хисап палатасы эшчәнлеге 257 материалда һәм телесюжетта тәкъдим ителде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетененда басылды. Хисап палатасы бюллетеньнары Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), шулай ук Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең “Россия Хисап палаталары” сайтында (http://www.ach-fci.ru) һәм Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең “АКСОР хәбәрчесе” (“Вестник АКСОР”) журналында урнаштырылды.

“АКСОР хәбәрчесе”нең 2010 елгы 2 санында “Фән һәм методология” бүлегендә Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовның

“Тикшерү-хисап органнары эшчәнлегендә мәгълүмати технологияләр” дип аталган мәкаләсе басылып чыкты.

Татарстан Республикасы Хисап палатасының рәсми сайтыннан алынган мәгълүматлар федераль мәгълүмат агентлыклары (РИА-Новости, Интерфакс-Поволжье, Прайм-ТАСС, ИТАР-ТАСС, РЕГНУМ һ.б.) тарафыннан кулланылды.